**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Йогышлылыгы югары булган кош гриппы таралуын һәм аның чыганакларын бетерүгә юнәлтелгән карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны тормышка ашыру буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 158 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Тукай районы Калмаш авылында урнашкан һәм «Фролов Эдуард Александрович» крестьян (фермер) хуҗалыгына кергән биналар территориясендә (алга таба – эпизоотия чыганагы) һәм Татарстан Республикасы Тукай районының Калмаш авылын, Яңа поселогын, Югары Байлар авылын кертеп, эпизоотия чыганагыннан 5 км радиустагы территория чикләрендә (алга таба – куркыныч янау зонасы) йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү сәбәпле имин булмауга һәм чирнең таралу куркынычына бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә (куркыныч янау зонасы территориясендә урнашкан кошчылык фабрикаларыннан тыш) карантин бетерелгән көннән 90 календарь көн дәвамында яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында»

2021 елның 23 ноябрендәге ПУ-894 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1018